**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

---

**26 декабрь 2024 ел** **№ 147**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Ивашкино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 82 номерлы карарына (җирлек Советының 27.08.2018 ел № 93, 15.11.2018 ел № 99, 26.10.2020 ел № 11, 17.11.2022 ел № 76, 31.01.2023 ел № 83, 20.03.2024 ел № 123 карары белән кертелгән

үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладзы күләме 13990 сум тәшкил итә»;

1.2. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 3 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Андреев Ф.П.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советының
2024 елның 26 декабрендәге
№ 147 карарына кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 19173 |